Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№36 (87)

14 ноябрь 2013 ел

## • Вакыйгалар эзеннән

**11 НОЯБРЬДӘ** ТРның Сәламәтлек саклау министры **А.ВАФИН**, ректор **И.ГАФУРОВ** һәм Фундаменталь медицина һәм биология институты директоры **А.КИЯСОВ** К.Маркс, 74 адресы буенча урнашкан бинадагы **РЕМОНТ ЭШЛӘРЕ** белән **ТАНЫШТЫЛАР**. Ремонт тәмамланганнан соң, бина Фундаменталь медицина һәм биология институты карамагына күчәчәк.

• • • •

Шушы көннәрдә Казанда бөек язучы **В.АКСЕНОВНЫҢ** тормышыюлыһәмиҗатына багышланган **БӨТЕНРОССИЯ ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ** үз эшчәнлеген башлап җибәрде. Бу чараны оештыру инициативасын КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты күрсәтте. Утырышлар В.П.Аксенов исемендәге музейда булды.

• • • •

**12 НОЯБРЬДӘ ТР ПРЕЗИДЕНТЫ Р.МИҢНЕХАНОВ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ КАЙГЫРТУЧАНЛЫК СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Анда КФУның үсеш перспективалары турында сөйләштеләр. Шулай ук Президент 19 яшь галимгә фәнни стипендия сертификаты, университетның кайбер хезмәткәрләренә Рәхмәт хатлары тапшырды. Бу исемлектә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының XX–XXI гасыр татар әдәбияты һәм укыту методикасы кафедрасы профессоры Т.Галиуллин да бар. Алга таба Кайгыртучанлык Советының яңа персональ составы сайланды. Очрашу азагында **КФУ** һәм **«АЛЬФА-БАНК»** ААҖ «Альфа-Шанс» уртак программасын гамәлгә ашыру; **КФУ, МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ** һәм **«SAMSUNG» КОМПАНИЯСЕ** белән IT нигезләр буенча өстәмә белем бирү программасын һәм «Samsung Junior IT & Software School» программалаштыруны кертү буенча килешүләргә кул куелды.

• • • •

**12 НОЯБРЬ** көнне **И.ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ** чираттагы **УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Тышкы элемтәләр буенча проректор **Л.Латыйпов** Кытай Халык Республикасына визиты, инновацион эшчәнлек буенча проректор **Н.Кашапов** Чехия Республикасына булган визиты, Территориаль үсеш һәм идарә институты директоры **Н.Баһаветдинова** Джакарту (Индонезия) шәһәренә булган визит турында мәгълүмат җиткерде. Алар җирле галимнәр белән очрашып, хезмәттәшлек күперен булдыруга ныклы нигез салган. 2014-2015 уку елына кабул итү буенча Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **С.Ионенко** сөйләде. Аның чыгышыннан соң, ректор чит ил студентларын күбрәк җәлеп итүгә басым ясады. Алга таба юридик факультет деканы **И.Тарханов** үзе җитәкли торган структур бүлекчәнең гражданлык һәм эшмәкәрлек хокукы кафедрасы исемен гражданлык хокукы һәм процессы кафедрасына; экология, эш хокукы һәм гражданлык процессы кафедрасы исемен экология һәм эш хокукы кафедрасына алыштыру идеясен тәкъдим итте. Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты директоры Р.Латыйпов үзенең институтында Олимпиадаларга әзерлек үзәген булдыру идеясен күтәреп чыкты. Ректорат барлык тәкъдимнәрне дә кабул итте.

• • • •

**13 НОЯБРЬДӘ** профессор **А.С.ШОФМАННЫҢ** тууына **100 ЕЛ ТУЛУ** уңаеннан **ХАЛЫКАРА ФОРУМ ЭШЛИ БАШЛАДЫ**. Ул 3 көн дәвам итәчәк. Анда бөек тарихчы, аның эшчәнлеге һәм шул мәсьәләгә бәйле проблемалар турында фикер алышу булачак.

• • • •

Тиздән КФУның барлык хезмәткәрләренә мәҗбүри рәвештә **ФЛЮОРОГРАФИЯ ТИКШЕРЕНҮЕ** узарга кирәк булачак. Аның өчен **18-22 НОЯБРЬДӘ** 08.30-13.00гә кадәр **«УНИКС», 25-26 НОЯБРЬДӘ** шул ук вакыт аралыгында **ИКЪТИСАД ҺӘМ ФИНАНС ИНСТИТУТЫ** янында **ФЛЮОРОГРАФИЯ** үткәрә торган **МАХСУС АВТОБУСЛАР** эшләячәк. Әлеге тикшерүне үтмәгән хезмәткәрләр 23 декабрьдән эш вазифаларын башкара алмаячаклар. Мөстәкыйль рәвештә үтүчеләр справкаларын 1 декабрьгә кадәр Хезмәт саклау бүлегенә алып барып бирергә тиеш.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*



Влад Михневский фотосы

# КФУда - бөек княгиня!

11 ноябрь көнне Казанга Рәсәй императорлар йорты җитәкчесе, җәмәгать эшлеклесе, бөек княгиня Мария Владимировна Романова (фотода үзәктә) килде. 12 ноябрьдә ул КФУга рәсми визит ясады. Княгиня Мария Романова ил буенча бик күп сәяхәт итә. Ләкин аның Татарстанга бик үзенчәлекле мөнәсәбәте сизелеп тора. Республикабызга соклануын яшерә алмый ул. Бигрәк тә тарихны саклауга зур игътибар бирелүен ассызыклады. «Хөкүмәт белән руханиларның килешеп эшләвен, конфессияләр балансын күрү бик сөендерде мине. Сез – башкалар өчен үрнәк», – дигән фикерләрен җиткерде кунак. *Дәвамы 2 биттә*.

• Бездә кунак бар

# КФУда - бөек княгиня!

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

Университетыбның тарихы, яшәеше, аның эшчәнлеге белән таныштыру максатыннан, княгиня өчен Тарих музеена экскурсия оештырылды. Кызыклы экскурсия, княгиня белән якыннан танышуга күчеп, очрашуга әйләнде. Мария Романова – Россиянең соңгы патшасы Николай II туганы, Россия императорларының нәсел дәвамчысы. Аларның жепләре Романовлар династиясеннән беренче рус патшасы Михаил Фёдорович Романовка барып тоташа.

Рәсәй императорлар йорты житәкчесе Оксфорд университетын тәмамлаган. Күпмедер вакыт Франциядә яшәгән. Хәзерге көндә Испаниядә гомер итә. 1989 елда, башка ир туганнары булмау сәбәпле, Россия тәхете варисы итеп билгеләнә.

Очрашуда ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, КФУ укытучылары, студентлар катнашты. Студентлар, тәэсирләрен яшерә алмыйча: «Бүгенге чарада булуыбызга чиксез шат. Тарих белән кызыксынуыбыз Романовлар династиясе вәкиле белән танышуны, аралашуны аеруча кызыклы һәм мавыктыргыч итте», – дип, фикерләре белән уртаклашты. Чыннан да, студентлар княгиняның визитына бик тә жаваплы караган: кунакка үзләренең истәлекле бүләкләрен әзерләве – моңа бер дәлил.

М.Романованың Татарстанга өченче тапкыр килүе. Бу юлы ТРның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев чакыруы буенча килгән. Княгиня Татарстанның популяр туристик урыннарының берсе – Свияжскида булган, Кремль белән танышкан. Республикабызда алган тәэсирләрен яшерә алмый ул. Казан федераль университетында узган очрашудан да бик канәгать.

* * *

*Россия тарихына зур үзгәрешләр алып килгән 1917 елгы инкыйлаб Романовлар династиясен дә урап узмый. Вакыйгалар башланганда, император гаиләсенең 65 әгъзасы була. Большевиклар тарафыннан аларның 18е, һәммәсе дә ир-егетләр, атып үтерелгән. Исән калганнар, 47 кеше, чит илгә китеп котылалар.*

• Дуслык күпере

Татар халкы үзенең кунакчыл булуы белән аерылып тора. Безнең университет та, белем йорты буларак, кунаклар килгәнне, аларны кунак итүне бик ярата. Бу көннәрдә без бүлектә чит илдән килгән укучылар белән очраштык.

# Очрашулар дәвамлы булсын!

**Алия ӘХМӘДУЛЛИНА,**
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Швейцариянең каникуллларын мәркәзебездә уздырырга теләкләрен белдергән өлкән сыйныф укучыларын Ш.Мәржәни исемендәге 2 татар гимназиясе директоры Камәрия Зиннур кызы Хәмидуллина һәм гимназия фонды житәкчесе Ландыш Хәмит кызы Фазуллина каршы алдылар, кунакларны Казаныбыз, республикабызның тарихи урыннары, Болгар кебек жирләрдә булганнан соң, кире үз илләренә кайтып китәр алдыннан, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтына алып килделәр. Швейцариянен Берн кантоныннан килгән уналты гимназия укучысы һәм житәкчеләре – тарих һәм рус теле укытучысы Клара ханым Сокол, француз теле һәм тарих укытучысы Адриан әфәнде Кунзи бернича сәгать буе татар милли мохитендә яшәде.

Без, Габдулла Тукай исемендәге Татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге студентлары, кунакларга кечкенә генә күңелле чара оештырып булдык. Инглиз теле укытучыбыз Алсу Хәлил кызы Әшрәпова татар халкының мәдәнияте, сәнгате, гореф-гадәтләре, йолалары, сыйнигъмәтләре белән таныштыруны алмаксат итеп куйды. Алып баручы кызларыбыз Айсылу белән Ильмира Татарстан белән Швейцариянең табигать, сәнгать, архитектурасында күп кенә уртаклыклар булуын ассызыклап киттеләр. Килгән кунакларыбыз Россиянең Мәскәү, Санкт-



Петербург шәһәрләрендә булганнар, әмма, әйтүләре буенча, Казан – аларга иң ошаган кала. Нигә, дигән сорауга, бик матур табигате, истәлекле урыннарга бай булуы, кунакчыл һәм ачык йөзле кешеләре белән күңелгә керде, дип жавап бирделәр. Швейцариядән килгән кунаклар да милли жырларын жырлап, үз сәнгатьләренә жәлеп иттеләр.

Бәйрәмнең иң истә калган мизгеле - татар халык биюен башкару һәм уеннар уйнау булгандыр, мөгаен. Бергәләп биюләр, түгәрәктә әйләнүләр вакытында кунакларның йөзендә барлыкка килгән елмаю, актлар залын яктыртып жибәргәндәй булса, әлеге милли уеннарыбыз безне берләштерергә, таныштырырга, аралаштырырга бер этәргеч булды. Йөзек салышы уены һәрберебезнең күңеленә хуш килде. Очрашу чәй өстәле артында дәвам итте. Кунакларны жимешле, сөтле чәй, татар халкының милли ризыклары – чәк-чәк, гөбәдия белән сыйладык. Очрашу ике ил мәдәнияте турында фикер алышулар белән бергә чит телдә аралашу мәйданчыгына әйләнде. Чит илдән килгән дусларыбызның кимендә 4-5 (швед, инглиз, француз, немец, итальян) телдә иркен сөйләшүдән тыш, рус телен өйрәнүләре бездә соклану хисе уятты. Иң куандырганы шул булды: бер укучы татар телен дә өйрәнә башлаган.

Игътибарга лаек әйберләр күп булды. Әйтик, швед теле дәүләт теле буларак теркәлмәгән, ләкин укучылар үз телләренә карата бик ихтирамлы, үзара да һәрвакыт туган телләрендә сөйләшәләр.

Очрашуда дуслашып бетеп, берберебез белән алга таба аралашу өчен, Интернет адресларын алмаштык, кунакка килү турында киләчәккә төрле планнар кордык.

Бәйрәм ахырында бераз моңсу булды: бер дә аерылышасы килмәде. Әмма яңадан күрешербез дигән өмет күңелләрне юатты. Минемчә, әлеге очрашу бездә алга таба үз телебезне яратып хөрмәт итәргә, мәдәниятебезне чит илләргә таныттырга этәргеч булды. Телләр белүнең алдыбызда яңа мөмкинлекләр ачкалын аңладык.

Бу очрашуны оештыручыларга барлык студентларыбыз исеменнән рәхмәт белдерәбез. Әле дә шул көнне алган позитив эмоцияләр белән яшәвебезне дәвам итәбез. Дуслык орлыклары тирән чәчелеп, уңышлары күзгә күренеп шыта да башласын дигән теләктә генә калабыз.

• Чара

# Көзге «Студентлар язы мәктәбе»

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Ишеттегезме? Белдегезме? Быел кыш булмый ди бит! Көздән язга күчәчәкбез! Дәлилләр әзләп торасы юк. Урамда көз булуга карамастан, язга хас жылы көннәр саклана. Радиодан да тыңладым, интернеттан да тикшердем: «Татарстан Республикасы гидрометеорология үзәге хәбәр иткәнчә, мондый жылы көннәр әле тагын бер атна дәвам итәчәк». Кояш та елмайгалап ала. Хәтта кайбер жирләрдә үги ана яфраклары да чәчәк аткан, ди бит! Вәт галәмәт!..

Арбаны жәйдән, ә чананы кыштан әзерлә, ди татар халык мәкале. Шуны истә тотып, 9-13 ноябрь көннәрендә Казаныбызда Идел буе Студентлар язы мәктәбенең I сессиясе үтте. Ә 13 ноябрь көнне Халыкара мәгълүмат үзәгендә 3 көн үткән чарага йомгак ясалып, гала-концерт узды.

Чара беренче тапкыр үткәрелүгә карамастан, аңа илебезнең 12 субъектыннан делегатлар килгән. Алар арасында Казан, Саратов, Ижау, Чебоксар, Пермь, Уфа һәм башка бик күп шәһәрләрдән талантлы, күңелендә ижат уты дөрләп торган йөздән артык студент катнашты. Россия яшьләр союзы һәм аның Татарстан бүлекчәсе белән берлектә уздырылган чара язын үтәчәк «Россия Студентлар язы» конкурсына әзерлекнең бер баскычы булып тора.

Өч көн дәвамында, белгечләр ярдәме белән, жыелган активистлар өчен дүрт юнәлеш буенча дәресләр үтте: вокал, хореография, оригиналь жанр һәм чаралар оештыру. Һәрбер семинар, мастер-класс, лекция ахырында иң актив студентлар ачыкланды.

Чараның ябылу тантанасына катнашучыларны котларга ТР яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрының урынбасары Р. Гарифуллин, «Россия Студентлар язы» программасының директоры А.Махнакова һәм Чечен Республикасының яшьләр эшләре һәм сәясәте министры Хож-Бауди Дааев та килгән иде. Р.Гарифуллин чарага килгән кунакларны сәламләде, проектта катнашучылар белән үз осталыкларын бүлешкән, тәжрибә уртаклашкан остазларга, ТР яшьләренә генә түгел, ә илебезнең башка субъектларыннан килүчеләргә дә ижади яктан үсәргә мөмкинлек биргәннәре өчен, зур рәхмәтләрен житкерде. Чарага Чечен Республикасыннан килгән мәртәбәле кунагыбыз да, Казанда беренче тапкыр гына булуына карамастан, үз хис-кичерешләре белән бүлеште. Республикабызда яшьләр белән эшләү тәжрибәсе, яшьләрнең үзләре белән танышып йөрүен әйтте.



13 ноябрь көнне үткән концертта катнашучыларга 4 категориядә дипломнар тапшырылды. Концертта студентлар тарафыннан башкарылган һәрбер бию, жыр, театраль күренеш РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре, продюсер, бөтенрәсәй «Россия Студентлар язы» фестиваленең музыкаль



юнәлештәге жюрие рәисе Андрей Билль, Россия телеканалында үткән «Большие танцы» проектының Казан командасы хореографы Алина Барилова, «Среда» телекомпаниясенең күнел ачу проектлары продюсеры Илья Собинов һ.б. житәкчелегендә әзерләнгән.

Мәркәзебез Казаннан ижат коллективлары галаконцертта сан ягыннан күп иде, үзләре сыйфат ягыннан да сынатмадылар. Тамашачы «Доминанта» вокал ансамблен, «Джеф стайл», «Микс стайл», үзбәк биюен башкарган кызлар бию коллективларына алкышларны кызганмады.

Катнашучыларны котларга килгән «Актерлык практикасы» мастер-классын оештыручы И.Ибатуллин: «Башлап йөрү һәрчак авыр, ләкин без мондый проектка күптәннән мохтаж идек инде. Чөнки һәр «Студентлар язы» фестиваленнән соң, сөйләнеп бетмәгән сүзләр кала иде. Менә бу проект шул бушлыкны тутырырга ярдәм иткәндер дип өметләнәм. Беренче коймакны төерле була, диләр. Ләкин безнең очракта ул бик тә тәмле һәм төерсез килеп чыкты», – дип билгеләп үтте.

Сүз уңаеннан, «Россия Студентлар язы» проекты житәкчесе А.Махнакова билгеләп үткәнчә, киләсе «Россия Студентлар язы» фестивале Тольятти шәһәрендә узачак, 2014 елның июнендә беренче халыкара «Студентлар язы» фестивале үткәреләчәк. Анда Шанхай Хезмәттәшлек оешмасы илләре дә катнашачак.

*Алсу Зиннурова фотолары*

● Яшьлек - яңарыш

# «Каз канаты» янә «канат кага»

1977 елда Габдрахман Сәлимов оештырган «Каз канаты» бию ансамбле заманында Казан дәүләт университеты студентлары арасында иң популяр ансамбль булган. Ул хәтта халык ансамбле исемен алуга ирешкән. «Нур» фәнни-җитештерү берләшмәсе ААҖнен Директорлар советы рәисе Зәһир Хөснимәрдән улы Исрафилов һәм профессор, КФУның татар журналистикасы кафедрасы мөдире Васил Зәһит улы Гарифуллин аны торгызып, яңа биючеләр туплады. «Каз канаты» янәдән канат кагарга талпына башлады.

**Диләрә БАТРШИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

«Монысы безнең «Каз канаты» бию ансамбле. Габдрахман абый бик сабыр остаз иде. Ул көйгә баса да белмәгәннәрдән чын биючеләр ясады...» Әниемнең студент чакта төшкән фотолары тупланган альбомын ачкан саен, мин нәкъ менә шул сүзләрне ишетә идем. Чөнки ул иң беренче оешкан «Каз канаты» бию ансамбле солистларының берсе булган. Ул, елмаеп, күңелендә саклангаһнарны исенә төшереп сөйләгән саен, мин бу ансамбльнең әнием өчен чыннан да бик якын, кадерле икәнен аңлыйм. Ул биегән коллектив яшәешен минем дә тоеп карыйсым, фотодагы төз гәүдәле егет-кызлар кебек очып-очып биисем килә иде. Бәхетемә, «Каз канаты» бию ансамбле мине дә чын мәгънәсендә үз канаты астына алды.

Ансамбль җитәкчесе Зәһир абый безнең һәр репетициябезгә килә, биегәнебезне читтән карап тора. Бәлки ул бу вакытта үзенең яшь, заманында әле яңа гына оешкан бию ансамбленең егет-кызлары җыелышкан чакларга әйләнеп кайтадыр.

Ни өчен ул «Каз канаты» ансамблен яңадан торгызырга булган? Бу хакта ул озаклап сөйләде: «Каз канаты» бию ансамбленең дәрәҗәсе республикабыз һәм аның төбәкләрендә генә түгел, ә ул вакыттагы СССРның күп кенә шәһәрләрендә дә югары иде. Безнең концертларда тамашачылар, эмоцияләргә бирелеп, шатлана, озаклап кул чаба, хәтта елый да иде. Без бит профессиональ биючеләр түгел, ә Казан дәүләт университетының төрле факультетларыннан җыелган студентлар гына. Репертуарыбыз күчле – ике дистәдән артык биючебез бар иде. Шуның өстенә барыбыз да тату булдык. Ул чактагы дуслыкны без әле дә югалтмыйбыз. Күрешкәч, озаклап сөйләшәбез, шунда ук үзебез өчен ансамбльнең иң популяр биюләрен башкарабыз. Дәресен әйткәндә, студент елларында иң истә калган мизгелләрне сорасалар, һәрберебез, берсүзсез, «Каз канаты» бию ансамбле, дип җавап бирәчәк.



Ансамбльгә йөргәндә кичергән хисләр, анда булган мизгелләрне сүзләр белән генә аңлатып бетереп булмый. Нәкъ менә шундый бай һәм горурланырлык тарихы булган «Каз канаты» бию ансамблен югалтасы килмәде. Бигрәк тә «Ул ансамбль инде юк, таралган», – кебек сүзләрне ишеткәч, аны яңадан торгызу нияте тагын да көчәйде. Ансамбльнең 35 еллыгына багышлап, «Каз канаты кауры-кауры» дип исемләнгән истәлекләр китабы чыгардык. Чираттагы адым да ясалды – бию ансамбле яңадан тупланды».

«Каз канаты» бию ансамбленең үзенә генә хас бер үзенчәлеге дә бар. Биредә һәр репетиция моңлы татар баянында уйнаган көйгә үтә. Моның нәрсәсе гаҗәпләнерлек дисезме? Иң мөһиме шунда, без төрле үрнәкләр ясап биегәндә, зал түрендә, баянның төймәләрен сикертеп, чын музыкантлар уйный. Аңа карап, без дә тырышып биергә ашкынабыз. Бу үзенә күрә бер милли дөнья, милли тормыш. Ансамбль җитәкчебез әйтүенчә: «Баянчы уен коралын үз кулына алса, көйне кирәк өлешеннән башлый, кызулыгын кимeтә яки арттыра, бернинә вариантта уйнап, бертөрлелектән китә ала. Яздырылган музыканы кулланганда, бу нечкәлекләргә ирешеп бетеп булмый. Ә иң мөһиме: тере тавышны берни дә алыштыра алмый!»

Биргә мине, бию белән берләттән, нәкъ менә әниемә охшыйсы килү теләге алып килде. «Каз канаты» бию ансамбле үзенең матур киләчәге белән кызыктырды, үзенә җәлеп итте.

Остазыбыз – Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Муса Җәлил ис. татар дәүләт опера һәм балет академия театры балетмейстеры, хореограф Фәнис Фәтхи улы Исмәгыйлев һәм университетыбызның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының С.Сәйдәшев ис. югары сәнгать мәктәбе студентлары Мәрьям Сафиуллина белән Айнур Таганов коллектив кызларына зуригътибар биреп, бию үрнәкләрен барлык нечкәлекләре белән өйрәтәләр. Лирик күңегүләр ясаганда, сыгылмалы гәүдәкуллар, югарыга омтылыш таләп итсәләр, кызу биюдә максималь дәрәҗәдә тиз темпка бирелергә өндиләр. Көй нинди булуга карамастан, биюче барлык мөмкинлекләрен эшкә җигәргә тиеш, дип аңлаталар алар безгә. Без репетицияләрдән соң, хәттә арымыйбыз да. Тырышып биегәннән соң, үзеннән канәгать калуга тагын ни җитә?

Әгәр сез дә биергә телисез икән, «Каз канаты» ансамблендә биергә теләүчеләрне көтеп калабыз. Сезне биредә бик җылы каршы алачаклар.

● Милләттәшләр

Уку атнасының ахыры җиту белән, туган йортка кайтып китәргә ашыгам. Шуннан рухланып, җаныма ял алып киләм. Тулай торактагы күршеләремнең берсе – уйгур, берсе – кытай татары. Бу егетләр бары тик җәйге каникулда гына туган җирләренә кайтып килә ала. Аларны кызганам: сагыну, юксыну ничек түзеп яшиләр икән? Ә бит аларны милләт рухы, татар җанлы булулары Татарстанда яшәтә икән! Кытай татары – Рифкать Әхәт улы Фәхретдин белән әңгәмәмне сезгә дә тәкъдим итәм.

# «Милләтем яшәеше якын миңа!»

**Кадрия ХӘСӘНОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



**– Рифкать, үзең белән таныштыр әле?**

- Мин Кытайның Шенҗаң Уйгур автоном районы Голҗа шәһәрендә туып үстем. Гаиләдә өч бала без: абыем һәм сеңлем бар. Әбибабаларым, әти-әнием - татарлар. Алар Кытайда туып үскәннәр. Мин Кытайда туган дүртенче буын татар вәкиле булам. Әтием – зәркән остасы, әнием дәүләт салым идарәсендә эшли.

**- Нәселегез җепләре Татарстанда кайсы якларга барып тоташа соң?**

- Әтинең бабалары - Кукмара ягыннан, ә әниемнең нәсел тамырлары - Апас районының Урта Балтай авылыннан. Бабамның бабасы моннан күп еллар элек, сәүдәгәр буларак, ерак Казахстанга чыгып киткән. Аннан Урумчида сату иткән, соңрак нәсел дәвамчылары - бабаларым Кытайның Уйгур автономияле төбәгендәге Голҗа шәһәренә килеп төпләнгәннәр.

**-Кытайда туып үскән егет белән рәхәтләнеп саф татар телендә аралашабыз. Моның төп сәбәпчесе гаиләдер инде?**

- Балалар бакчасында, мәктәптә уку-укыту, китаплар, гәҗитжурналлар чыгару, телевидение тапшырулары - бездә барысы да кытай һәм уйгур телләрендә алып барыла. Балалар бакчасына йөрмәдем. Әтинең әнисе белән бергә яшәдек. Мине әбием үстерде. Аның белән татарча сөйләшүем нәтиҗәсе бу.

**- Кытай хөкүмәтенең андагы татарларга карата мөнәсәбәте ничек?**

- Хәзерге көндә Кытайда татарларга карата хөрмәт һәр адымда чагыла. Милләттәшләребез тарихларын, тамырларын, милли үзаңын саклап яшәү бәхетенә ирешә. Татарларның Кытайда иң аз санлы милләт булуына карамастан, хөкүмәт телебезне, мәдәниятебезне саклап калу өчен ярдәм итәргә тырыша! Кытай халык республикасы җитәкчелегенә чиксез рәхмәтләребезне әйтәбез.

**- Мәктәпкә укырга кергәч, кыен булмадымы соң?**

- Гаиләдә гел татар телендә генә аралашсак та, торган җир теле - кытай телендә дә иркен сөйләшәбез. Әле сигезенче сыйныфка кадәр уйгур мәктәбендә укыдым. Анысы да ана теле кебек якын. Уникенче сыйныфны кытай мәктәбендә тәмамладым (Кытайда унике ел уку тәртибе – *Х.К.*).

**- Аннан соң юл турыдан-туры Татарстанга булдымы?**

- Башта мин Пекин сәнгать университетына имтиханнар тапшырдым. Шул ук вакытта күңелдә Казанга китү уе да яшеренеп ята иде. Аңа этәргеч биргән кеше - Голҗа шәһәрендәге татар җәмгыятенең мактаулы рәисе Ильяр Габитов. Ул, татар зыялылары Миркасыйм Госманов, Рабит Батулла, Разил Вәлиев ярдәме белән 2003 елда Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев белән очрашып сөйләшкән. Сүз барышында Кытайда яшәүче татар яшьләренең туган телләрендә уку мөмкинлекләре булмау, тарихи ватаннарында югары белем алуны оештыру мәсьәләсен күтәргән. Президент бу фикерне хуплагач, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты аны чынга ашыру эшен башлады. 2005 елның 24 августында без, 36 егет һәм кызлардан торган бер төркем Кытай татарлары, Казанга килү бәхетенә ирештек.

**- Икенче мохиткә ияләшү нечегрәк булды?**

- Әлбәттә, авырлыклар очрамый калмады. Әйтергә кирәк, Татар конгрессы безне үзенең ярдәменнән ташламады. Башта бер ел буе КХТИга әзерлек курсларына йөрдек, рус телен өйрәндек. Иң кызыгы шул булды: рус телендә аралаша алмавыбыздан көлделәр. Башта, ничек инде Татарстанда кешеләр рус телендә аралаша, дип гаҗәпләнә идек. Кытайда вакытта татар илендә бары тик туган телдә генә аралашачакбыз, дигән хыяллар чәлпәрәмә килде, ныклап рус телен үзләштерергә керештек.

**- Уку программасын үзләштерүдә дә каршылыкларга очрагансыңдыр инде, чөнки барысы да рус телендә...**

- Әйе, бик кыен кабул итә идем. Ташламалар ясадылар, тик бу берничек тә безне акламый. Мин үзем, мәсәлән, имтихан вакытында аңлаган кадәресен татарча сөйли идем. Әгәр укытучы татар телен бөтенләй белмәсә, тәрҗемәче белән имтихан тапшырдым. Хәтта дипломны да татарча яклад ым. «Без ике дәүләт телле башкалада яшибез, мин татарча яклыйм», - дип әйттем. Казанда һәрбер кеше дә русча белергә тиеш, дип уйлыйлар. Ялгыш фикер бу, Татарстанда бөтенесе дә татарча белергә тиеш, дигәне менә колакка ятышлырак.

**- Сагыну хисе Казанда төпләнеп калу уен куып тараткан чаклар да буладыр...**

- Сагынмаган бер генә минут та юк. Якын булса да торган җир, сагындыра туган җир, диләр бит. Тик барыбер Казанда каласым килә. Милли мохит үзенә тарта.

*Рифкать Татарстандагы Кытай татарларының студентлар җитәкчесе урынбасары булып тора икән. Казан университетларындагы Кытайдан килгән татар студентларының зур ярдәмчесе, уң кулы ул. Нинди генә мәсьәләләрдә дә аларга ярдәм итәргә әзер. Татарстанда туып та, туган теленең, татарлыкның кадерен белмичә, «урыслашып» беткән яшьләргә Рифкать бер дигән үрнәк күрсәтә. Афәрин, Рифкать!*

● Әдәби сәйләннәр



Ильмира Камаева – Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең 4 курсында укый. Азнакай районы Урманай авылында туып үскән, шигырь дулкыннарында тирбәлүче әлеге кыз бар нәрсә белән дә кызыксына... Фән өлкәсе, фотога төшерү, психология һәм, әлбәттә, иҗат. Төрле бәйгеләр, конференцияләр, кызыклы очрашуларда да актив катнаша. Бүген исә газетабыз укучылары хозурына үзе язган берничә шигырен тәкъдим итә. Ильмира шушы көннәрдә генә С.Сәләйманова исемендәге стипендиягә лаек булды. Аны уңышлары белән дә котлыйбыз!

## Кил әле...

*Тәрәзгә яңгырлар чиртkәндә,*
*Болытларны кояш үпкәндә,*
*Зәңгәр кыңгыраулар чәчәк атып,*
*Таң җиленнән җылы көткәндә,*
*Бер кил әле миңа, болай гына...*
*Җилләр күңелләрне өткәндә.*

*Табигатьнең матур мизгелендә*
*Ләйсән яңгыр өмет иткәндә,*
*Сайрар кошлар бер-берсенә язын*
*Чырык-чырык нидер дәшкәндә...*
*Түгел, күзге моңсу кичтә*
*Яңгыр кулчатырны үпкәндә,*
*Шул вакытта җылы язлар булып,*
*Бер керәп чык үтеп киткәндә.*

* * *

*Гомер буе нидер эзлибез без:*
*Бала чакта юк-бар сәбәпләр.*
*Үсә төшкәч егет кызәтәбез –*
*Бераз үзгәрә шул гадәтләр.*

*Яшьлек никтер балачакны эзли,*
*Гомер көзе эзли яшьлекне.*
*Чәчәк аткан мизгел, мәхәббәтле*
*Шундый ихлас матур чак дипме.*

*Ә чынлыкта бар да вакытлыча,*
*Һәр нәрсәнең була алмашы.*
*Дөнья куар өчен түгел, бәхеткә дип*
*Тусын җиргә адәм баласы!*

* * *

*Тормышымның язылмаган көе,*
*Җырланмаган җыры бар әле.*
*Язмышымның – миңа көтелмәгән,*
*Бик шатлыклы, серле бүләге...*

*Җырланачак җырым бул син, әйдә,*
*Язылачак дәртле көем бул!*
*Күзләремнән алма күзләреңне,*
*Йөрәгемә кочле кулың куй!*

## Югалма

*Тәрәздә боз өреп*
*Сурәтең төшерәм*
*Пыялага.*
*Сулышым бик кайнар,*
*Хисләр дә...*
*Боз кебек тиз эреп*
*Югалса?..*

*Танышлык гадәтчә:*
*Телефон номеры*
*Кулларда.*
*Мәхәббәт үрләде*
*Йөрәктә,*
*Ак чәчәк сибелде*
*Юлларга.*

*Таптым да -*
*Шатландым!*
*Әйдәле,*
*Син башка*
*Югалма.*

* * *

*Бер кайгыга, бер шатлыкка илтә диләр,*
*Көздән кышка таба юлларны.*
*Сары яфрак чыңы һаваларда*
*Шуның көен җырга урадым.*

*Синнән башка, әйе, синнән башка,*
*Көзге паркларны урармын.*
*Урамнарда, бакчаларда күрсәм,*
*Яшь парларга бәхет юрармын.*

*Алтын сары яфракларны җыеп,*
*Бер бәйләмгә аны урадым.*
*Сары сагышларга түгел, бәхетемә*
*Илтсен иде көзге юлларым.*

* * *

*Көтелгәнчә булды быел көзләр:*
*Шундый салкын, шыксыз, караңгы...*
*Учларыма кысып борчуларны*
*Рәхәтләнеп елап булмады.*

*Яңгыр елый көн дә тәрәзәмдә,*
*Яфрак ява иртә-кичләрен.*
*Киткән кошлар кире кайтыр да бит,*
*Мәхәббәтсез мин соң нишләрмен?!*

*Кайнар сулыш өреп, күңелемне*
*Эретерлек сүзләр тапмадың...*
*Соңгы хәбәр әнә истәлеккә –*
*Өстәл өстендәге хатлармы?!*

*...Кулчатырым ачып, тыныч кына*
*Таныш түгел юлдан атладым...*
*Кышны синнән башка башлармын.*

● Киңәш-табыш

# Көз - ачык төстәге зонтиклар чоры

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Ноябрь, гадәттә, күңел төшү һәм боеклык вакыты булып санала. Стереотиплардан арыныр чак житте!

### Туклану

Көз – кышкы салкыннар алдыннан организмны ныгыту һәм үзүзеңне карау өчен менә дигән вакыт. Бу – уңыш һәм витаминнар муллыгы, тәнәфесләр, ачык төсләр, җәй турындагы җылы хатирәләр һәм киләчәккә зур планнар кору чоры да. Сәламәтлегебез өчен әллә ни күп кирәкми: нибары дөрес туклану, даими хәрәкәт һәм күтәренке кәеф!

Иң яхшы көзгә диета ул – диетаның булмавы! Сентябрьдән башлап, организмыбыз калорияләр таләп итә. Бу юкка түгел. Салкын, яңгырлы көннәрдә аппетитның яхшы булуы даими ашыйсы килү галәмәте түгел, ә гадәти күренеш. Көзен терлек, кош һәм балык итен күбрәк ашарга киңәш ителә. Алар витаминнар, аксым, май кислотасына бай була. Ә бу элементлар саулыгыбыз өчен гаять мөһим. Бу ризыклар иммунитетны ныгытырга, эшчәнлек сәләтен арттырырга һәм һәрвакыт актив булырга ярдәм итәчәк. Дөрес, вакытлыча иттән тыелып тору организмга унай тәэсир итә. Әмма көз вегетарианлык өчен бик үк яхшы вакыт түгел.

Табигый антибиотиклар турында да онытырга ярамый. Кәрән, суган, сарымсак элек-электән салкын тиюдән ярдәм иткән. Керәндә С витамины цитруслыларга караганда 5 тапкыр күбрәк. Аны хәл беткәндә һәм арып киткәндә файдаланалар. Көзен кибет киштәләре төрле яшелчә, җиләк-җимеш белән тулы була. Аларны рационга күбрәк кертеп җибәрергә кирәк.

### Күтәренке кәеф

Һәр эш көнебез стресстан башлана. Без һәрвакыт ашыгабыз, шулай да соңга калабыз. Вакытны алдар өчен, нибары ярты сәгатькә иртәрәк торырга кирәк. Шушы 30 минутның 10 минутын иртәнге ашның тәмен белеп ашау өчен файдаланырга кирәк. Тагын 20 минутка физик күнегүләр ясауга сарыф итәргә мөмкин. Күңелле музыкага берничә хәрәкәт ясап алу көне буена кәефне күтәрәчәк һәм энергиягә баетачак.

Уянып бетәр өчен, тагын бер яхшы чара – салкын душ. Гадәти иртәнге душтан соң, берничә градуска түбәнрәк булган су белән коеныгыз. Әкренләп су температурасын тагын да төшерегез.

Әлбәттә, мондый режим билгеле бер дәрәҗәдә түземлелек һәм тырышлык таләп итәчәк. Иң авыры – беренче 20 көндә түзү. Бу сынау срогын узу белән, иртәнге зарядка һәм уятып җибәрә торган салкын душ файдалы гадәткә әвереләчәк.

Көзнең һәр көне саен кояш яктысы кимегәннән кими бара. Йөргән җирдән йокыга талмас өчен, хә-



рәкәтләнергә кирәк. Әгәр көн матур икән, укудан яки эштән кайтканда, бер тукталышны булса да җәяү үтегез. Көндәлек җәяү йөрү – сәламәтлекне ныгыту өчен менә дигән чара! Тренажерлар залына йөрү дә файдага гына булачак. Даими физик күнегүләр кыш буена артык авырлык җыюдан саклар. Бассейнга абонемент алыгыз. Йөзгәндә, бөтен төрле мускуллар эшли, умыртка сөягенә, буыннарга авырлык килми. Су – менә дигән гидромассаж: тән сыгылмалы һәм шома була, кан йөреше яхшыра, матдәләр алмашы тизләнә.

Илһамланып алырга да онытмагыз! Музыка тыңлагыз, рәхәтләнеп биегез! Фантазияне эшкә җигеп, инде туйдырырга өлгергән чәч прическасын, аяк кимен алыштырыгыз. Ачык төсләрдәге зонтикны ачып җибәрсәң, иң шыксыз яңгырлы көн дә алай ук ямьсез тоелмаячак.

Иң мөһиме, елмаерга онытмаска! Чөнки кәефебезнең күтәренкелеге күп очракта үзебездән тора.

● Бер дулкында

## Халыкның рухы – сәнгать әһелләрендә!

**Динә МӨХТӘСИПОВА**

Шушы көннәрдә Татарстан Язучылар берлегендә бәйрәм булды. Алар зур кунаклар – иҗатташ дусларын, Башкортстан Язучылар берлеге әгъзаларын кабул итте.

Очрашу кысаларында узган концертта язучы-шагыйрьләребез үзләренең җырбиюгә оста икәнлекләрен дә күрсәтте.

Сәхнә түренә бер-бер артлы иҗат әһелләрен юморист Алмаз Хәмзин чакырып торды. Р.Батулланың сәхнәгә тальян гармун күтәреп чыкканын күргәч, бер кат тын калдык. Йөрәкләрнең иң нечкә кылларын тибрәтерлек итеп уйнады Рабит абый. Драматург Р.Сәгъди Т.Миңнуллинның икке әсәреннән җыр башкарды. Ә С.Әхмәтҗанова оста биюче икән. Шагыйрә Ш.Җиһангированың моңлы тавышын ишетү үзе бәхет булды. Телеэкраннар аша тискәре рольләрдә күреп өйрәнгән Ә.Камалиев бөтенләй башка яктан ачылды.

Татарстан белән Башкортстан арасындагы дуслык күперен ныгыту икенче көнне рәсми очрашуда дәвам итте. Семинарда яшь язучыларның иҗатлары белән танышып, аларга ике республика язучылары бәя бирде. Чараның максаты итеп, союзга яшьләрне тарту билгеләнгән иде.

Семинарда катнашкан күренекле җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре Р.Вәлиев чыгышында: «Элек бездә – Башкорстан, сездә – Татарстан көннәре уза иде. Ә хәзер аралашу житми. Безнең бүләсе әйберебез юк. Халыклар өчен иҗатчылар якынлыгыннан да яхшырак әйбер юктыр. Халыкның рухы – сәнгать әһелләрендә», – дип фикерләре белән уртаклашты.

**13 ноябрь көнне Татарстан Язучылар берлегендә «Иделем акчарлагы – 2013» яшь иҗатчылар конкурсының ачылыш тантанасы булды. Бәйгенең йомгаклау турына үткән 43 яшь язучы арасында безнең уку йорты студентлары да бар. Җиңүчеләр 15 ноябрь көнне билгеле булачак.Бу хакта тулырак алдагы санда укыгыз.**

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ЖЧЖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.